Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР

2022 елның 29 декабре №42

Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы , «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләр башлыкларына, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларына, депутатларга, үз вазыйфаларын даими нигездә башкаручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә айлык акчалата түләү күләмнәрен һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларын арттыру турында» 2022 елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Карары, Татарстан Республикасында депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 17 декабрендәге 1015 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 05 июнендәге 13 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә, Сәрдекбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 29 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып (алга таба – Нигезләмә), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 16 390 |

б) 3.1 пунктының беренче абзацында «11498» санын «11958» санына алыштырырга;

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 17 390 |

г) Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең билгән муниципаль вазыйфасына карап, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи окладына калдыксыз бүленә торган күләмдә 12688 сум күләмендә вазыйфаи окладлар билгеләнә.»;

д) Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Муниципаль хезмәткәркә вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләүләр түләнә, җирле үзидарә органнары

структурасын үзгәртеп корганда, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую очрагыннан тыш, бу очракта акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакын элек ул биләгән вазыйфалары буенча акчалата хезмәт хакы күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла».

г) 4 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 18 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карар, гамәлдә булуы 2022 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла торган әлеге карарның 1 пунктындагы «а» һәм «б» пунктчаларыннан тыш, 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Сәрдекбаш авыл җирлеге башлыгы: И.М.Нәбиев